**Татар теле дәресенә технологик карта.**
**5 нче татар сыйныфы.**
Укытучы: Фәрхетдинова Л.Ф.

| | |
|---|---|
| **Тема** | **Сузык авазлар** |
| **Максат** | 1. Укучыларны сузык аваз хәрефләре белән таныштыру;<br>2. Сузык авазлар турында булган белемнәрне камилләштерү;<br>3. Үзара ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү; күренекле шагыйребез М.Җәлил иҗатына мәхәббәт тәрбияләү. |
| **Планлаштырылган нәтиҗә** | Сузык авазларның ясалышын, кайсы сүздә һәм кайсы иҗектә ничек ясалуын, дөрес язылышын белү, аларны язуда дөрес куллана белү.. |
| **Төп төшенчәләр** | Сузык авазлар, транскрипция. |
| **Предметара бәйләнеш** | Татар әдәбияты, рус теле |
| **Эшне оештыру төрләре** | Фронталь, парларда ,төркемнәрдә эшләү |
| **Чыганаклар :**<br>**- төп** | 1. Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова-Казан:Татар. Китап. Нәшр., 2015 |
| **- өстәмә** | 1. Презентация Power Point<br>2. Карточкалар. |

| **Дәрес этаплары** | **Дәрес этабының максаты** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре (УУГ)**<br><br>**ШУУГ** –шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре<br><br>**РУУГ**- регулятив универсаль уку гамәлләре<br><br>**ТБУУГ**- танып белү универсаль уку гамәлләре<br><br>**КУУГ**-коммуникатив универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|---|
| **Оештыру. Эшкә кызыксыну тудыру** | Укытучы өчен максат:<br><br>психологик уңай халәт барлыкка китерү | Балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру.<br><br>Эш ритмына кертү.<br>Укытучының сөйләме.<br>Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.<br>Укытучы өчен максат: балаларда яхшы кәеф, эшлисе килү халәте тудыру. Моның өчен укучылар белән әңгәмә үткәрү. Укучылар 4әр кеше утыралар.Алларында**<u>Мэнэдж мэт.</u>**<br>Исәнләшү, хәерле көн теләү.<br>*-Яныгыздагы иптәшегезгә**Кояшлы көн теләгез,***<br>*- Каршыдагы иптәшегезгә*<br>***Хәерле көн** теләгез,*<br>*- Бер-берегезгә яхшы теләкләрегез өчен рәхмәт әйтегез.*<br>- *Укучылар! Бер-беребезгә* | Укучылар:<br><br>- Исәнмесез! Хәерле көн сезгә! | КУУГ: классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | *елмаешып алыйк. Дәресебезне күтәренке кәеф белән башлап җибәрик.* | | |
| **Белемнәрне актуальләштерү**<br><br>**Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру** | Укытучы өчен максат:<br>яңа материалны үзләштерүгә кызыксыну уяту<br>Укучылар өчен максат: сузык авазларның төрләрен ачыклау | Белем дәрәҗәсен тикшерү .<br>1.Типик җитешсезлекләрне билгеләү. Укытучы өчен максат: Үткән теманы аңлау дәрәҗәләрен ачыклау, үзләштерү.<br>-*Балалар, сезгә өй эше итеп кайсы күнегү бирелгән иде?*<br>(Өй эшен карап чыгу)<br>-Экрандагы җөмләләрне укыйбыз,нәтиҗә ясыйбыз:<br>*1. Авазлар язуда...белән күрсәтелә?*<br>*2. Авазларны... һәм ... .*<br>*3. Хәрефләрне ... , ... Һәм ... .*<br><br>*2.-Балалар, әйдәгез сузык авазларның моделен төзегез әле.*<br>*-Димәк сузык авазлар....* | Укучылар өчен максат: өй эше дөреслеген тикшерү.(138 нче күнегү)<br>*138 нче күнегү*<br>- *Укучылар хәрефләре төшеп калган сүзләрне укыйлар, кагыйдәләрне әйтеп, нәтиҗә чыгаралар*<br>- *Укучыларның җаваплары тыңлана.*<br>***1. Авазлар язуда хәрефләр белән күрсәтелә?***<br>***2. Авазларны әйтәбез һәм ишетәбез .***<br>***3. Хәрефләрне язабыз , күрәбез Һәм укыйбыз .***<br>-Укучылар такта алдында эшлиләр, модель төзиләр,аңлаталар<br>Сузык авзлар:<br>-калын сузыклар(арткы рәт)<br>-нечкә сузыклар (алгы рәт)<br>-иренләшкән сузыклар<br>-иренләшмәгән сузыклар һ.б | ТБУУГ: күнегүдәге хәрефләре төшеп алган сүзләрне уку, сүзләрдәге сузык авазларны аерып алу, аларның ясалуын, әйтелү үзенчәлекләрен аңлау<br><br>РУУГ: булган белемнәрне истә тотып гамәлләр кылу<br>КУУГ: тыңлый белү, коллектив фикер алышуда катнашу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Уку мәсьәләсен кую** | Укытучы өчен максат:<br><br>яңа белемнәр кабул итүне оештыру һәм үзләштерүгә юнәлеш бирү<br><br>Укучылар өчен максат: килеп туган уку мәсьәләсен анализлау; дәреснең темасын, максатын билгели белү | Проблемалы ситуацияне китереп чыгару.<br>*Алдыгыздагы дәфтәр битенә Сезнеңчә ничек ? Кайсы авазлар әһәмиятлерәк, кирәгрәк?Сузык авазлармы әллә тартык авазлармы?*<br>-*Ә хәзер бер әкият тыңлагыз.Әлеге әкияттән шул ук сорауга җавап эзләгез.* ***Сорау:*** - *Сезнеңчә ничек ? Кайсы авазлар әһәмиятлерәк, кирәгрәк?)*<br>*Бер заман тартык авазлар белән сузык авазлар бәхәсләшкәннәр.*<br>- *Әлбәттә, без кирәгрәк! Бездән башка кеше авызын да ача алмый! – дип кычкырганнар сузыклар.*<br>- *Анысын карарбыз әле!- дип, каршы чыкканнар ди, тартыклар. – Бер дә авызыңны ачмыйча әйтеп кара әле безне. Барып чыкмаячак!*<br>- *“М” дип авыз ачмыйча да әйтеп була!*<br>- *Шул бер “М” нан башка бер авазны да авыз ачмыйча әйтә алмаячаксыз.*<br>- *Барыбер без кирәгрәк, - дигәннәр сузык авазлар.- Бер иҗек тә, бер сүз дә бездән башка була алмый. Без үзебез генә дә сүз була алабыз: Ә? И! Уу, ууы, О!*<br>- *Сездән башка иҗек тә, сүз дә булмый- анысы дөрес. Сез бездән башка гына берәр сүз әйтеп карагыз* | Максатлар куя, дәрес темасын формалаштыра.<br>-*укучылар язып куя, 1-2 укучы үз фикерен җиткерә* | **Регулятив:** максат кую;**коммуникатив:** сораулар кую;**танып белү:** *гомумуку* – танып белү максатын үзлектән билгеләү; *логик*-проблеманы билгеләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | *әле. Мәсәлән: Татарстанның башкаласын.*<br>- *А-а, - дигәннәр сузыклар һәм тынып калганнар.*<br>- *Күрдегезме инде, бернәрсә дә аңлар хәл юк бит! Менә без үзебез генә дә "Кзн" дип әйтәбез икән, һәркем Казан икәнен чамалый алачак.*<br>- *Ярар, яхшы. Алайса бездән башка гына Башкортстанның башкаласын әйтеп карагыз әле! – дип көлешкәннәр сузыклар.*<br>*Тартыклар , шәм утын сүндерергә тырышкан кебек, "Ф! Ф!" дип азапланганнар да, бернәрсә барып чыкмагач, башларын аска иеп тынып калганнар , ди.*<br>*Әлеге әкияттән соң сездә нинди фикерләр туды. Кайсы авазлар әһәмиятлерәк, кирәгрәк?Сузык авазлармы әллә тартык авазлармы?*<br>*(Укучылар төркемнәрдә фикер алышалар, үз җавапларын группада дәлиллиләр. Укытучы җавапларны сорый.)*<br>*-Җавапларыгыз өчен рәхмәт.* | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Түбәндәге сүзләргә игътибар итегез әле , бу сүзләрдәге сузыкларның әйтелешендә нинди аерма бар? (егет,ел,юл,люстра,шахтёр,клеенка,ял, яфрак)<br>-Димәк, (слайд№9) *е,ё,ю,я хәрефләре ике аваз кушылмасын белдерә*<br><br>-Димәк,бүгенге дәресебезнең темасы нинди?<br>- Әйе, дәресебезнең темасы: **сузык аваз хәрефләре.**<br>Дәрескә нинди максат куярсыз? (һәр төркем үзенә максат куя)<br>- Түбәндәге сүзләрдә а авазы ничек әйтелә? (Азат, Альберт) | *Укучыларның җаваплары:е,ё,ю.я хәрефләре ике аваз кушылмасын белдерә*<br>*-егет сүзендә е хәрефе ике аваз кушылмасын белдерә.*<br><br>*-Азат, Альберт сүзләрендәге беренче а авазы олашып әйтелә.*<br><br>- сузык аваз хәрефләренең ясалышы, әйтелеше, язылышы турында дөрес итеп аера белү. | ТБУУГ: танып белү мәсьәләсен мөстәкыйль ачыклау һәм максат кую<br><br>РУУГ: кагыйдә, инструкуцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу<br><br>КУУГ: коллектив фикер алышуда катнашу |
| **Танып-белү эшчәнлеге. Уку мәсьәләсен чишү.** | Укытучы өчен максат:<br><br>сүзләрдә е , ё, ю, я хәрефләренең ике аваз кушылмасын белдерүен аңларга ярдәм итү<br><br>Укучылар өчен максат:<br>сүзләргә транскрипция ясау,кагыйдәне чыгару. | 1 нче бирем.<br>142 нче күнегү. “Серле сандык” уены<br>-Әйдәгез бер уен уйнап алабыз:<br><br>Е.ё,ю,я хәрефләрен транскрипциядә дөрес итеп күрсәтергә. (147 нче күнегү)<br><br>**2 нче бирем(төркемнәрдә эш)**<br>**1) Е хәрефенең э авазын һәм ике аваз кушылмасын белдерү** | 1 нче бирем. 142 нче күнегү. “Серле сандык” уены<br><br>(слайд№11,<br>**Кагыйдә.**<br>.1) **Татар сүзләренең беренче** | ТБУУГ: уку мәсьәләсен чишүдә логик фикерләү, төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру<br><br>КУУГ: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү<br><br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **очракларына 5 шәр мисал язарга.**<br>**2) Кайсы сүзләрдә а сузыгы о-лаштырып әйтелә, шул очракка 6 мисал язарга.**<br><br>-Үзебез белгәннәрдән чыгып, сузык авазлар турында кагыйдә чыгарып карыйк. | **ижегендә а (о) сузыгы әйтелә.Язуда ул а хәрефе белән күрсәтелә.**<br>**2) э авазы сүз һәм ижек башында э хәрефебелән; сүз, ижек уртасында һәм ахырында е хәрефе белән белдерелә.**<br>**3) Е, ю, я хәрефләре икешәр аваз кушылмасыннан тора.** | |
| **Физкультминут ка** | | - Хәзер МИКС-ФРИЗ-ГРУП эшләп алабыз. (сорауга җавап булган санга берләшеп басарга)<br>- Ничә хәреф икешәр аваз кушылмасыннан тора? (3)<br>- Калын сузыклар ничәү? (4)<br>- Бала сүзендә ничә сузык аваз бар? (2) | | РУУГ: булган белемнәрне истә тотып гамәлләр кылу<br>КУУГ: тыңлый белү, үз фикереңне булдыру, биремдә катнашу |
| **Яңа белемнәрне ныгыту** | Укытучы өчен максат:<br>яңа мәгълүмат туплауда **эзләнү** алымын куллану;<br>белемнәрне ныгыту мөмкинлеге булдыру | 3 нче бирем. Шигырьдә сүз нәрсә турында бара? Шагыйрь нәрсә әйтергә тели?<br>Тыңлау"Батырлык турында"<br>*Беләм, егет, синең җырыңда*<br>*Күп илеңә сөю, якынлык.*<br>*Тик әйт: авыр сугыш елында*<br>*Син күрсәттең нинди батырлык?*<br>*Син бастыңмы сафка, кыенлык,*<br>*Кайгы йөген илең тартканда?* | 3 нче бирем.<br><br>Экрандагы шигырьне укыйлар, тыңлыйлар һәм сорауларга җавап бирәләр:<br>-Батырлык турында<br>- | РУУГ: үзконтроль, биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү<br><br>ШУУГ: бер-береңә ярдәм итүдә таныл белү инициативасы күрсәтү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Укучылар өчен максат: яңа белемнәрне камилләштерү | *Кыенлыкта күренә кыюлык,*<br>*Ил батырны сыный батканда*<br><br>**Эзләнү эше.**<br>***Шигырьдәге сүзләрне укыгыз.***<br>Слайдта бирелгән схемага нигезләнеп шигырьдән сүзләр язарга.<br><br>**Нәтиҗә** | Шигырьдә е, ё,ю,я хәрефләре кергән сүзләрне укыйлар.<br><br>Укучыларның җаваплары. | КУУГ: мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек инициативасы күрсәтү, үз гамәлләреңне бәяләү |
| **Яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану һәм тикшерү** | Укытучы өчен максат: яңа белемнәрне мөстәкыйль куллану мөмкинлеге булдыру<br><br>Укучылар өчен максат: алган белемнәрне практик куллана белү | Тактада командалар ярышы<br>-сүз башында э, сүз уртасында э гә мисаллар языгыз. **(144 нче күнегү)**<br><br>**Проект эшләү:**<br>Проблемалы ситуацияләрне эзләп табуны оештыру. | Эремчек электр,элек, эт, кечкенә, керпе һ.б. | ШУГГ: үз мөмкинлекләреңне белү-белмәү чикләрен чамалау<br><br>ТБУУГ: фикерләүдә логик чылбыр төзү<br><br>РУУГ: кагыйдә, инструкуцияләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу ,эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү<br><br>КУУГ: коллектив фикер алышуда катнашу<br><br>**РУУГ:** планлаштыру, прогноз ясау; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Дәрестә өйрәнгәннәр буенча мини проект эшләү. (реклама формасында)<br><br>***Таймд пэа шэа*** *структурасы буенча фикер алышабыз... бер-берегезгә рәхмәт әйтегез.*<br>*Укытучы берничә кешедән сорый. Урыннарга утырабыз.* | Максатка ирешү планын төзиләр һәм чараларын билгелиләр ( алгоритм, модель һ.б.)<br>(Өйрәнгән кагыйдәләргә нигезләнеп, проект эшләү) | ТБУУГ: модельләштерү, *логик*-проблемаларны чишү, логик фикерләү чылбырын төзү, дәлилләү, гипотеза һәм аның нигезен күрсәтү;<br>**КУУГ:** мәгълүматны эзләүдә һәм сайлауда инициатив хезмәттәшлек. |
| **Уку эшчәнлеген йомгаклау.** | Укытучы өчен максат: дәрестәге эшчәнлекне анализлау, белемнәрне бәяләү һәм киләчәккә перспектива билгеләү<br><br>Укучылар өчен максат: үз фикереңне дәлилләү, дәрестә алган белемнәрнең әһәмиятен аңлау, аларны киләчәктә куллана белү<br><br>Укытучы өчен максат: өй эшен хәбәр итү, аны башкару ысулын аңлату | 1. Рефлексия.<br>**5 нче бирем.**<br>**Тест. Дөрес җавапны туры китереп, йолдызчыклар куеп барыгыз, шуларны тоташтырыгыз.**<br><br>- Бүгенге дәрескә нинди максат куйган идек? Максатыбызга ирешә алдыкмы?<br>-Бүген алган белемнәребез тормышта кирәк булырмы?<br>2. Белемнәрне бәяләү. (һәр укучы билгеләр куя. Билгеләр белән укытучыны таныштыралар)<br>-Шәхси крточкаларга билгеләр куябыз.<br>3. Өй эше.<br>151 нче күнегү<br>Б) я, ю, е хәрефләре кергән сүзле мәкальләр язарга.<br>В) Иҗади эш (149 нчы күнегү) | **5 нче бирем.**<br>**Үзләрен тикшерәләр һәм бәялиләр.**<br><br>-Сузык авазларны дөрес итеп аера белү, аларның ясалышын, әйтелешен һәм дөрес язылышын аңлау. | ШУУГ: үз уңышларың / уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү<br><br>РУУГ: үз эшчәнлегеңне контрольгә алу<br><br>КУУГ: үз фикереңне төгәл һәм тулы итеп әйтә белү<br>ТБУУГ:рефлексия;шәхси: нәтиҗәләр чыгару |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Укучылар өчен максат: өй эшен дөрес башкаруга әзерлек | 4. Дәрес тәмам, укучылар. Сау булыгыз! | | |